| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

28.07.2023 Казан ш. № 2053-р

Татарстан Республикасы “Казан шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә газ бүлү челтәре объектының саклык зонасын урнаштыру турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «УнистройДом» төзелеш компаниясе» махсуслашкан йорт салучы ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» ДБУның (27.07.2023 № 04А-04/1836) хатын искә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карар чыгарды:

1. Гомуми мәйданы (8071 ± 31) кв.м. территорияне тәшкил иткән 16:16:120602:1245, 16:16:120602:1248, 16:16:120602:1249, 16:16:120602:1250, 16:16:120602:1251, 16:16:120602:1254, 16:16:120602:1255, 16:16:120602:1261, 16:16:120602:1262, 16:16:120602:1263, 16:16:120602:3725, 16:16:120602:3738, 16:16:120602:3774, 16:16:120602:867, 16:16:120602:869, 16:16:120602:871, 16:16:120602:10624, 16:16:120602:10625, 16:16:120602:10626, 16:16:120602:10627, 16:16:120602:10628, 16:16:120602:9626, 16:16:120602:1256, 16:16:120602:868, 16:16:120602:393 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, газ бүлү челтәре объектының саклау зонасын («Казан ш.нең Совет районындагы Мамадыш трактындагы торак комплексында газүткәргеч төзелешенең 1 нче һәм 2 нче чираты, кадастр номеры 16:16:120602:7597») урнаштырырга.

2. Бүлгеч газүткәргеч объектының эксплуатация срогында саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Газ бүлгеч челтәрләрне саклау кагыйдәләрен раслау турында” 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**